Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлегенең башкарма комитеты

# КАРАР

14 февраль 2019 ел № 3

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Башкарма комитетының «2016-2020 елларга Чыты авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа ярдәм итү «Муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2016 елның 14 мартындагы 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Башкарма комитетының «2016-2020 елларга Чыты авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа ярдәм итү «Муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2016 елның 14 мартындагы 4 номерлы карарын Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон белән тәңгәлләштерү максатларында Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Башкарма комитетының «2016-2020 елларга Чыты авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа ярдәм итү «Муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2016 елның 14 мартындагы 4 номерлы карары атамасында һәм текстында тиешле урыннарда килешләрдәге «максатчан» сүзен төшереп калдырырга.
2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Башкарма комитетының «2016-2020 елларга Чыты авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа ярдәм итү «Муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2016 елның 14 мартындагы 4 номерлы карарының 3 бүлегендәге 5 пунктында «муниципаль заказ» сүзләрен «муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алуларга» алмаштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе С.Ә. Фәйзрахманов